# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Петровский Завод авыл җирлеге составына керүче Петровский Завод авылында 2024 елда үзара салым кертү турында

31 март 2024ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Сарман муниципаль районы Петровский Завод авыл җирлеге башлыгының 20.03.2024 «Сарман муниципаль районы Петровский Завод авыл җирлегенең Петровский Завод торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында” 2023 елның 15 ноябрендәге 1 номерлы, “Сарман муниципаль районы Петровский Завод авыл җирлегенең Петровский Завод торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында” 2023 елның 15 ноябрендәге 2 номерлы карарларына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча “Сарман муниципаль районы Петровский Завод авыл җирлегенең Петровский Завод торак пунктында гражданнар җыенын 2024 елда билгеләү турында» Сарман муниципаль районы Петровский Завод авыл җирлегенең Петровский Завод торак пунктында гражданнар җыены

КАРАР БИРДЕ:

1. «Сарман муниципаль районы Петровский Завод авыл җирлегенең Петровский Завод торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 15 ноябрендәге 1 номерлы, «Сарман муниципаль районы Петровский Завод авыл җирлегенең Петровский Завод торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында» 2023 елның 15 ноябрендәге 2 номерлы карарларына түбәндәге редакциядә үзгәрешләр кертергә:

«1. Тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны (Петровский Завод торак пунктында урам тышкы яктырту челтәрләрен ремонтлау (лампалар, таймерлар, энергия саклаучы яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру);

2. Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (Петровский Завод торак пунктында юлларны кардан чистарту (килешү буенча машина йөртүченең эшләренә һәм хезмәтләренә түләү), (Петровский Завод торак пунктынын Үзэк урамы юлын ремонтлау (таш белән капланган чокырлы ремонт, вак таш сатып алу, ташу, салу, килешү буенча хезмәтләргә түләү);

3. Петровский Завод торак пунктында традицион күмү урыннарын ремонтлау, коймалар төзү, төзекләндерү (территорияне чабу һәм коры агачларны кисү, триммер

өчен ягулык-майлау материаллары, запас частьләр һәм чыгым материаллары сатып алу, килешү буенча хезмәтләр өчен түләү; зират территориясен саклау өчен материаллар сатып алу, килешү буенча хезмәтләр өчен түләү);

4. Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (Петровский Завод торак пунктында су күтәрү скважинасынын территориясен һәм насос өчен будканы саклау өчен койма тотарга материаллар сатып алу, буенча хезмәтләр өчен түләү);

5. Торак пункт территориясен төзекләндерү (Петровский Завод торак пункт территориясендэ улэн чабу (килешү буенча хезмәтләр өчен түләү); триммерлар өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу; тракторны тоту (Беларус МТЗ 82.1 тракторы өчен ягулык-майлау материаллары, запас частьлар, чыгым материаллары сатып алу, килешу буенча хезмәтләр өчен түләү, балалар мәйданчыгын койма урнаштыру очен материаллар сатып алу, килешу буенча хезмәтләр өчен түләү; трактор өчен косилка сатып алу; территорияне чабу өчен триммерлар сатып алу;

6. Петровский Завод торак пунктында янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгын сүндерү янчыкларын сатып алу)?»

2. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Петровский Завод авыл җирлеге Советының мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән,Татарстан Республикасы хокукый мэгълумат рэсми порталында http: //pravo.tatarstan.ru., Сарман муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында http: //sarman.tatarstan.ru. кабул ителгәннән соң җиде көн эчендә бастырып чыгарырга.

Халык җыенында рәислек итүче
Сарман муниципаль районы
Петровский Завод авыл җирлеге башлыгы Р.Р.Нуртдинов